ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2021 Казан ш. № 468-135/кс-2021

«Коммунальный сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 № 240-73/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, ташландык су агызуга 2022-2025 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай кеременә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «Коммунальный сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 № 240-73/кс-2020 карарына 1 нче кушымтага үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 № 240-73/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2021 № 468—135/кс-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Коммунальный сервис» ҖЧҖ өчен 2021-2025 елларга ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Лаеш муниципаль районы | | |
| 1 | «Коммунальный сервис» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 28,84 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 30,03 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 30,03 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 35,77 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 35,77 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 42,74 |
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 42,74 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 48,65 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 48,65 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 49,07 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге